Дүртенче чакырылыш ТР Питрәч муниципаль районы
Советының унбишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 сентябрь, 2021 ел № 104

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 31 августындагы бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чыты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 23 декабрендәге 38 номерлы карарының (2018 елның 30 гыйнварындагы 91А номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары

белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов